ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 16.08.2022 1076 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма
комитетының «Безнең яңа башлангыч сыйныф
укытучысы» Алабуга муниципаль районы
Башлыгы грантын бирүне гамәлгә кую турында»
2022 елның 18 июлендәге 914 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 272-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» федераль закон нигезендә, кадрлар потенциалын үстерүгә юнәлдерелгән муниципаль ярдәмне көчәйтү һәм Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының педагогик кадрлары формалаштыру максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Безнең яңа башлангыч сыйныф укытучысы» Алабуга муниципаль районы Башлыгы грантын бирүне гамәлгә кую турында» 2022 елның 18 июлендәге 914 номерлы карары белән расланган, «Безнең яңа башлангыч сыйныф укытучысы» Алабуга муниципаль районы Башлыгы гранты турындагы Нигезләмәгә (алга таба-Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.2 пунктындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-төп гомуми белем турында аттестат булу;»

1.2. Нигезләмәнең 4.3 пунктындагы 1 абзацта «15 июльдән 15 августка кадәр» сүзләрен «1 июльдән 31 июльгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Нигезләмәнең 2.1.1 пунктындагы 5 нче кушымтасында китерелгән Килешүне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1.1. «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Алабуга институтында билгеләнгән, «Башлангыч сыйныфларда укыту» белгечлеге буенча курс бәясе нигезендә, «Казан (Идел буе) федераль

университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Алабуга институты каршындагы көллияттә белгечлек буенча белем алган өчен түләүне Алабуга муниципаль районы бюджетыннан Грант алучыга субсидия рәвешендә бирүне гамәлгә ашырырга».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Л.Р. Яһудинга йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 5DD9ADE894A62EB7F6C4DA0DBC7098E466BA

Владелец: Нургаянов Ленар Фаридович

Действителен с 03.12.2021 до 03.03.2023

Л.Ф. Нургаянов

.